МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 сентябрь 2019 ел № М 399

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча комиссия төзү турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив төстә хәл итү максатында «Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча комиссия төзү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында» 2019 елның 15 августындагы 682 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча комиссия төзергә (алга таба – комиссия).

2. Расларга:

1) комиссия турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Сан алуга шәһәр халкын күбрәк тартуны тәэмин итү максатында Башкарма комитетка:

1) дәүләт статистика органнарына билгеләнгән тәртиптә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча төзелеш төрен (торак яки торак булмаган фонд) һәм аның кайсы оешма, предприятие балансында торуын күрсәтеп, адреслар исемлеген актуальләштерү һәм оештыру планнарын төзү өчен торак урыннары саны һәм яшәү урыны буенча торак урыннарында яшәүче һәм теркәлгән затлар саны турында мәгълүматлар тапшырырга;

2) муниципаль берәмлекләрдә урам исемнәренең, йортларның номерлары һәм фатирларның номерлары булуын тәэмин итәргә.

4. Шәһәр Хакименең түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү турында» 2008 елның 26 маендагы 210 нчы карар;

2) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү турында» 2008 елның 26 маендагы 210 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2008 елның 30 июнендәге 261 нче карар;

3) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү турында» 2008 елның 26 маендагы 210 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2009 елның 5 маендагы 226 нчы карар;

4) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү турында» 2008 елның 26 маендагы 210 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2010 елның 25 гыйнварындагы 11 нче карар;

5) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү турында» 2008 елның 26 маендагы 210 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 1 июнендәге 275 нче карар.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2019 елның 17 сентябрендәге
М 399 нчы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны
әзерләү һәм үткәрү буенча комиссия турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча комиссия (алга таба – комиссия) дәүләт хакимияте, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының килешенеп эш итүләрен координацияләү һәм тәэмин итү һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны (алга таба – 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу) әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив төстә хәл итү өчен төзелгән.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив-хокукый актларына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге нигезнамәгә таяна.

3. Комиссия составы шәһәр Хакиме карары белән раслана.

2 бүлек. Комиссиянең бурычлары

4. Комиссиянең төп бурычлары:

1) шәһәр территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының, федераль һәм региональ башкарма хакимият органнарының килешенеп эш итүләрен тәэмин итү;

2) 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле мәсьәләләрне оператив төстә хәл итү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен:

1) шәһәр территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү барышына контрольне гамәлгә ашыра;

2) шәһәр территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрүнең барышы турындагы мәсьәләне һәм аның оператив нәтиҗәләрен карап тикшерә;

3) шәһәр территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрүнең оештыру планын раслый;

4) түбәндәге сораулар буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә:

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү эшенә төрле оештыру-хокукый формадагы оешмаларны җәлеп итү;

- халык турында мәгълүматлар җыюга, шулай ук халык турында мәгълүматларны эшкәртүгә гражданнарны җәлеп итүне оештыру;

- халык турында мәгълүматлар җыюга җәлеп ителгән затларны укыту һәм эшләү өчен кирәкле мебель һәм элемтә чаралары белән җиһазландырылган, саклана торган бүлмәләр белән тәэмин итү;

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр белән тәэмин итү;

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү өчен кирәкле транспорт чаралары, элемтә чаралары бирү;

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү өчен кирәкле картографик материалларга төгәллек кертү;

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу эшләрен гамәлгә ашыру өчен, аларның ресурсларыннан һәм бүлмәләреннән файдалану максатында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрне җәлеп итү, шул исәптән халык санын интернет аша алуда катнашу өчен Бердәм дәүләт хезмәтләре порталына керә алу мөмкинлеге бирү;

- халык турында мәгълүматлар җыючы затларның иминлеген тәэмин итүне, 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклауны оештыру;

- торак комплексларының ябык территорияләренә, гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык берләшмәләренә керә алуны тәэмин итү һ.б.;

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуга кагылышлы басма агитацион материалларны урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар бүлеп бирү;

- җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында халык санын алуда катнашуга җәлеп итү;

- Татарстан Республикасының территориаль башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча төзелеш төрен (торак яки торак булмаган) һәм аның кайсы оешма, предприятие балансында торуын күрсәтеп, торак һәм торак булмаган фондлардагы йортларның саны турында мәгълүматлар, адреслар исемлеге һәм оештыру планнары төзү өчен торак урыннарының саны һәм яшәү урыны буенча торак урыннарында яшәүче һәм теркәлгән затлар турында мәгълүматлар тапшыру;

- 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләгәндә һәм үткәргәндә территориядә мәгълүмати-аңлату эшләре үткәрүне оештыру.

6. Комиссия түбәндәге хокукларга ия:

1) үз утырышларында Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү барышы турында Яр Чаллы шәһәре буенча федераль һәм региональ башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләрен тыңларга;

2) Яр Чаллы шәһәре буенча федераль һәм региональ башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан билгеләнгән тәртиптә кирәкле документларны соратып алырга;

3) комиссия эшенә федераль һәм региональ башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, фәнни, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар, гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләре, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итәргә;

4) комиссиягә йөкләтелгән бурычларны хәл итү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне карау өчен эшче төркемнәр төзергә.

7. Комиссия комиссия рәисеннән, рәиснең ике урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, комиссия утырышлары планын раслый һәм комиссия составын яңарту буенча тәкъдимнәр кертә. Комиссия рәисе булмаганда яки аның кушуы буенча рәис вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасарының берсе үти.

8. Комиссия утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә, ләкин эш планы нигезендә ярты елга бер тапкырдан да ким түгел. Комиссия утырышлары аларда әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашканда гына үткәрелә.

9. Комиссия карарлары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш җыюы нәтиҗәсендә кабул ителә.

10. Комиссия карарлары утырышта рәислек иткән комиссия рәисе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2019 елның 17 сентябрендәге
М 399 нчы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Мәһдиев<br>Наил Гамбәр улы | комиссия рәисе, Яр Чаллы шәһәре Хакиме |
| Абдуллин<br>Ринат Әзһәр улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| Кропотова<br>Наталия Анатольевна | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| Гедминас<br>Альбина Наил кызы | комиссия секретаре (килешенү буенча), дәүләт статистикасы буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Яр Чаллы шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | |
| Әдһәмова<br>Лилия Шәүкәт кызы | Хаким Аппараты (Шәһәр Советы) оештыру-аналитик һәм хокукый эшләр идарәсе башлыгы |
| Әгъләмов<br>Ирек Рим улы | «Россия почтасы» ФДУП филиалы – «Татарстан почтасы» Федераль почта элемтәсе идарәсенең Яр Чаллы районара почтамты башлыгы (килешенү буенча) |
| Әхмәтҗанов<br>Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы |
| Әхмәтова<br>Гөлнар Карл кызы | Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| Баязитов<br>Фәнис Идрис улы | «Россия милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомствоара сак идарәсе» Федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомствоара сак хезмәте бүлеге башлыгы, полиция полковнигы (килешенү буенча) |
| Быданова<br>Татьяна Александровна | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешенү буенча) |
| Вәлиев<br>Дамир Шамил улы | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол һәм Тукай районнарының хәрби комиссары (килешенү буенча) |
| Варго<br>Елена Юрьевна | «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Яр Чаллы филиалы җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Викулов<br>Сергей Михайлович | Россия ЭЭМ идарәсенең миграция мәсьәләләре буенча Яр Чаллы шәһәре буенча бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Вилданов<br>Азамат Илдус улы | Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге башлыгы |
| Галимов | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |

| | |
|---|---|
| Искәндәр Нургаләм улы | |
| Галиуллин<br>Рөстәм Рәфыйк улы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгы |
| Гыйззәтуллин<br>Ленар Рәис улы | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы |
| Гыйлаҗева<br>Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| Жандарова<br>Юлия Владимировна | «Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлеге башлыгы |
| Закиров<br>Надир Дамир улы | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| Закирова<br>Лира Вәли кызы | «Ростехинвентаризация Федераль Техник инвентаризация бюросы» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы производство участогы башлыгы (килешенү буенча) |
| Зарипов<br>Айдар Салават улы | «Россия җәзаларны үтәтү Федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесенең Комсомол районы буенча филиалы башлыгы, эчке хезмәт майоры (килешенү буенча) |
| Зарипова<br>Равилә Гыйльметдин кызы | Башкарма комитет карамагындагы «Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| Зыятдинов<br>Рафаил Хафиз улы | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| Ильясов<br>Рәшид Флүр улы | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Үзәк һәм Автозавод районнарының хәрби комиссары |
| Исхаков<br>Илмир Зөфәр улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| Каширина<br>Галина Михайловна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| Кислов<br>Александр Иванович | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| Мингалимова<br>Гөлнара Галимҗан кызы | «Татарстан Республикасы Техник инвентаризация бюросы» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы филиалы директоры (килешенү буенча) |
| Миннегалиев<br>Мөдәрис Харис улы | Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| Миннәхмәтова<br>Лилия Шәмсемхәмәт кызы | дәүләт статистикасы буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Яр Чаллы шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлеге башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| Мөхәмммәтҗанова<br>Римма Равил кызы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| Сәгыйдуллина<br>Ирина Алексеевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| Сәлмәнов<br>Ленар Ирек улы | «Шәһәр төзелешен үстерү хезмәте» муниципаль унитар предприятиесе директоры |

| | |
|---|---|
| Ситдыйков<br>Салават Әнәс улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| Фәсхетдинов<br>Радик Рөстәм улы | Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Фатыйхов<br>Нияз Шамил улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Фәхретдинова<br>Светлана Зиннур кызы | Башкарма комитетның хисап һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Хәлимов<br>Рамил Мәрван улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| Харисов<br>Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |
| Хуҗин<br>Рөстәм Нияз улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| Шәфигуллина<br>Олеся Рәдиф кызы | «Россия җәзаларны үтәтү Федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесенең Автозавод районы буенча филиалы башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы (килешенү буенча) |
| Юмагулов<br>Рөстәм Наил улы | «Татарстан Республикасы буенча янгынга каршы федераль хезмәтнең 15 нче отряды» федераль дәүләт казна учреждениесе башлыгы (килешенү буенча). |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.И. Андреева